**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

16.10.2024 1127-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 17 ноябрендәге 1251-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча административ регламентына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 17 ноябрендәге 1251-п номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 23 августындагы 731-п номерлы, 2022 елның 28 ноябрендәге 1138-п номерлы, 2023 елның 14 мартындагы 264-п номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

2. Хокукый тәэминат бүлегенә шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.А. Тугушевка йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
2024 елның 16 октябрендәге
1127-п номерлы боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 17 ноябрендәге 1251-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.6.1 пунктта:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зоналары чикләре турында санитар саклык зоналары проектында билгеләнгән белешмәләр ( санитар саклык зоналары чикләренең урнашу урынының текст һәм график тасвирламасы, җирле координаталар системасында әлеге чикләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге) – Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен билгеләнгән XML форматындагы электрон документлар рәвешендә.»;

сигезенче һәм тугызынчы абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

2.6.4 пунктында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, Регламентның 2.6.5 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла);».